| | |
|---|---|
| **ГЛАВА<br>ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ЛӘКЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
2024 ел 30 нчы октябрь

**КАРАР**
№ 6

Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә
2025 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Фермы
Сәүкле торак пунктында халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгы

КАРАР чыгарды:

1. 2024 елның 15 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы, Фермы Сәүкле авылы, Тукай урамы, 2 нче йорт янында урамда 20245елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегенең Фермы Сәүкле авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Фермы Сәүкле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән гражданнар,сроклы хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт үтәүчеләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме:

1) Фермы Сәүкле торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру(лампаларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча түләү);

2) Фермы Сәүкле торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм эшләр өчен түләү).

"ӘЙЕ " " КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Антонов Ю.Г.